ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2020 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авылы җирлегенең Иске Чуаш Адамы авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

2019 елның 29 ноябре № 10

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Емелькино авылы җирлеге Иске Чуаш Адамы авылында гражданнар җыены нигезендә

Карар:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авылы җирлегенең Иске Чуаш Адамы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, (I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлар) 300 сум күләмендә үзсалым кертергә

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

**Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- Иске Чуаш Адамы авыл юлларын агымдагы төзекләндерү (вак таш, ЩПС сатып алу, вак таш салу, грейдлау, торбалар алу);

**Күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- Иске Чуаш Адамы авыл чикләрендә урамнарны яктыртуны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу
- Иске Чуаш Адамы авылы буасын ремонтлау (товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу)

3. Әлеге карарны Емелькино авылы җирлегенең мәгълүмат стендларында, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында: htt://pravo.tatarstan.ru

Емелькино авылы җирлеге башлыгы
ТР Аксубай муниципаль районы Н.И.Михайлова